СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                                   КАРАР

03.04.2024 г.          с. Шеланга          № 37-209

«Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең
Шилангы авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар
җыенының 28.10.2023 ел № 16 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы авылы территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 13 апреленә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авылы җирлеге Шилангы авылы территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 октябрендәге 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:
- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм

электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (урам яктыртуын ремонтлау) ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Йорт янындагы территориядә гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Шилангы авылы, Энергетиклар ур., 19 йорт, 12:20 сәгатьтә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров